**Татар гомуми белем бирү оешмаларында укучы балалар өчен**
**татар теленнән республика олимпиадасының**
**муниципаль туры сораулары җаваплары**
**2017-2018 уку елы. 5 нче сыйныф**

**Үткәрү вакыты - 90 минут**
**максималь балл – 60**

## I. Тестлардан берәр дөрес җавапны билгеләгез.

1. Иренләшкән сузык авазларның барысы да кулланылган рәтне билгеләгез. (2 балл)

а) йөзем, болыт, төтен, бүре, куян;
**ә) урман, тоз, үрдәк, вагон, сөлге;**
б) сүзлек, төлке, бүрек, боз, кул;
в) үсемлек, юлбарыс, көлке, конфет, йокы.

2. Парсыз саңгырау тартыклардан гына торган рәтне билгеләгез. (2 балл)

а) [п], [ф], [т], [с], [ш], [ч], [к], [къ];
ә) [х], [ң]; [ц], [һ], [щ];
**б) [ц], [щ], [х], [һ], [’];**
в) [л], [р], [w], [й].

3. Җөмләдәге ирен гармониясе чагылыш тапкан сүзләр саны дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. (2 балл)

*Бераздан йорт артындагы түгәрәк ялан өстенә, тыныч кына сузылып яткан олы юл өстенә җиңел генә, күренер-күренмәс кенә булып, кичке томан ятьмәләре эленде.* (Г.Бәширов)

а) 2;
**ә) 3;**
б) 4;
в) 5.

4. **Текстка** дөрес аңлатма бирелгән рәтне билгеләгез. (2 балл)

а) иясе дә, хәбәре дә булган җөмлә;
ә) тиңдәш кисәкләре булган җөмләләрнең рәттән килүе;
б) берничә җөмләдән торган һәм мәгънә ягыннан бер-берсенә бәйләнмәгән сөйләм;
**в) берничә җөмләдән торган һәм мәгънә ягыннан бер-берсенә бәйләнгән сөйләм.**

5. Ясалма сүз кулланылмаган җөмләне билгеләгез. (2 балл)

а) Бүлмәнең бер почмагында торган пианино артында ниндидер кыз утыра. (Л.Шәех)
ә) Анда ерткыч җанварлар юк, сине ашамаслар. (Г.Камал)
**б) Йомшак сүз әйтеп бәйләсәң, сынган сөяк тә ялгана. (Мәкаль)**

в) Бакчадагы алмагач корый яңгыр яумагач. (Н.Дәүли)

6. **Саналмышка** дөрес аңлатма бирелгән рәтне билгеләгез. (2 балл)
а) кушма саннар;
**ә) сан ачыклаган исем;**
б) сан алдыннан килгән сүз;
в) сан ачыклаган фигыль.

7. Калын хәрефләр белән бирелгән исемнәрнең үзенчәлекләрен билгеләгез. (2 балл)

***Җиреннән*** *аерылган җиде ел елар,* ***иленнән*** *аерылган үлгәнче елар.* (Мәкаль)

а) урын-вакыт килешендә, I зат тартым белән төрләнгән, берлек санда;
ә) чыгыш килешендә, II зат тартым белән төрләнгән, берлек санда;
**б) чыгыш килешендә, III зат тартым белән төрләнгән, берлек санда;**
в) чыгыш килешендә, тартым белән төрләнмәгән, берлек санда.

8. Юклыктагы боерык фигыль кулланылган мәкальне билгеләгез. (2 балл)
а) Башта уйла, аннан сөйлә. (Мәкаль)
ә) Түләүсез малның кадере булмый. (Мәкаль)
б) Акыллы кешедән акыллы сүз чыгар. (Мәкаль)
**в) Авыз эчендә ботка пешермә. (Мәкаль)**

9. Аергыч кулланылган мәкальне билгеләгез. (2 балл)
а) Дөнья яктыра көн белән, адәм яктыра белем белән. (Мәкаль)
**ә) Акылсыз авызны ачарга ачкыч кирәкми. (Мәкаль)**
б) Эшең эш булса, күңелең тыныч булыр. (Мәкаль)
в) Тел кылычтан үткен. (Мәкаль)

10. Тиңдәш кисәкләре булган гади җөмләне билгеләгез. (2 балл)
а) Бөтен урам шаулап-гөрләп тора. (Г.Бәширов)
ә) Барыбыз да шат, куанычның иге-чиге юк. (Г.Бәширов)
**б) Әнием еламаска тырышты, иреннәрен кысты. (Н.Дәүли)**
в) Урам бушады, бөтен җир тынып калды. (Р.Габделхакова)

## II. Башыгызны эшләтегез.

Алдан да, арттан да бер төрле укыла торган, шул ук вакытта **К** хәрефенә башланган, **К** хәрефенә беткән 6 сүз уйлап языгыз. (калак, кадак, кабак, как, кебек, күк...) (6 балл)

## III. Теоретик бирем.

Сыйфатларның дөрес язылышын аңлатыгыз, мисаллар китерегез. (10 балл)

## IV. Гамәли-иҗади бирем.

*Картлар сүзен кар басмас.* (Мәкаль)

1. *Сүзен* сүзенә фонетик анализ ясагыз. (4 балл)

2. Җөмләдәге сүзләрнең кайсы сүз төркеменә караганлыгын билгеләгез. (4 балл)

3. *Картлар, кар* сүзләренең антонимнарын языгыз. (4 балл)

4. Җөмлә җыйнакмы, әллә җәенкеме? (2 балл)

5. Әлеге тема белән бәйле фикерләрегезне 12-15 җөмләдән торган бәйләнешле текст итеп языгыз. (10 балл)

Текст язуга таләпләр:
- текст төзелеше ( башлам, төп өлеш, йомгаклау);
- җөмләләр дөрес, төзек булырга тиеш;
- язма телнең  бай, сурәтле булуына  игътибар итәргә;
- орфографик грамоталылыкка игътибарлы булырга.